Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Сосна авыл җирлегенең Түбән Сосна торак пунктында ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2019 елның 1 декабре №2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" Татарстан Республикасы 45-ФЗ Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Сосна авыл җирлегенең Түбән Сосна торак пунктында үткән үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Халык җыены карар итте:

1. "90 % ташлама каралган I группа инвалидлар, ялгыз яшәүче өлкән кешеләрдән, балигъ бала тәрбияләүче тулы булмаган гаиләләрдән тыш, Сосна авыл җирлегенең Түбән Сосна авылында яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр гражданга 2020 нче елда үзара салымны 600 сум күләмендә кертергә.
2. Алынган акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- Түбән Сосна авылында урам- юл челтәрен норма таләпләренә туры китерү,

- зиратларга капкалар сатып алып урнаштыру,

- Герой Сәрвәр урамында балалар уен мәйданчыгы төзү өчен җир кишәрлекләрен рәсмиләштерү, мәйданчыкка җиһазлар сатып алып урнаштыру.

3. Халык җыены нәтиҗәләрен Сосна авыл җирлегенең мәглүмати стендларында урнаштырырга , «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталы» интернет – ресурсында һәм Татарстан Республикасы Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Балтач муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә (baltasi.tatarstan.ru).

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Сосна авыл җирлеге башлыгы Ф.С.Габдрахманов